Республика Татарстан
Менделеевский муниципальный район
Совет Ижевского сельского поселения
423647, с. Ижевка, ул. Советская, д. 25
ИНН 1627001020, КПП 162701001
ОКПО 02790667

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Ижевка авыл җирлеге советы
423647, Ижевка авылы Совет урамы, 25
ИНН 1627001020, КПП 162701001
ОКПО 02790667

Тел. (факс): (85549) 3-67-89 e-mail: igev.Men@tatar.ru

# Р Е Ш Е Н И Е

18 .12.2023 ел № 120

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 гыйнварендагы 82 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.5 статьяның 17 пунктын үз көчен югалткан дип танырга
- 2.5 статьяның 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классны чин бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru " Ижевка авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Ижевка авыл җирлеге Советы рәисе Мәсәгутова Р.Т.